# ЧИШМӘ БАШЫ

“ Туган телне сөючеләр” нең матбугат үзәге

Февраль, 2025 ел
№2

*Бу сан сәхифәләре*

- ✓ *Ватанны саклаучыларга багышлана*
- ✓ *Туган телләр айлыгы*
- ✓ *Герой-шагыйрь Муса Җәлил*
- ✓ *Әфган - йөрәк ярасы*
- ✓ *Гражданлык-патриотик айлыгы*

## Гранданлык-патриотик ае

*“АҖАГАН” УЕНЫ*












**Газетаны оештыручы һәм баш редактор:** Гариф Ахунов исемендәге Казанбаш төп гомуми белем мәктәбе татар теле һәм әдәбияты укытучысы : *Габдрахманова Л.М.,*
китапханәче: *Рәхимова Р.З.*

**Редколлегия әгъзалары:** *Гатауллина Г.Ф., Әсхәдуллина Г.Җ., Рамазанова Ф.Р.*

**Индекс-** 422023
**Тираж-** 10 данә

**Адрес:** ТР,Арча районы, Казанбаш авылы, Мәктәп урамы, 94

### Февраль - ир-атлар ае

Гыйнвар белән саубуллашып
Кышны тәмамлаган ай.
Миңа калса февраль ае
Ир-атларныкы бугай!

Уянуга без кояшны
Сәламлибез иң элек.
Февраль ул солдат шикелле
Уенда тик иминлек!

Ә тугызынчы февральне
Ничек оныттык туган.
Үлемсез әсәрләр язган
Фәнис Яруллин туган.

Җәлил ае дип атасак
Ризалаша бар кеше.
Герой –шагыйрьне биргән көн
Февральнең нәкъ унбише.

Батырлык мәңгелек юлдаш,
Дөрес аңлагыз мине.
Февральнең егерме өче
Илдә армия көне.

Суык диеп зарланмыйлар,
Йөзләре нурдан туа.
Февральнекеләрнең беләм,
Җаннары җылы була.

Буранлы, хисле,төннәрен
Язларга карый ае.
Хатын-кызлар, килешегез,
Февраль-ир-атлар ае!

**Таһир Шәмсуаров**

### ВАТАННЫ САКЛАУЧЫЛАРГА БАГЫШЛАНА...

**Кадерле ир-егетләр!**
**Сез бит безгә таяныч һәм ныклы терәк!**
**Сездә генә курку белмәс олы йөрәк!**
**Ир-егетләр, бүген сезне котлар өчен,**
**Күңелләргә тулышкандыр күпме теләк!**
**Сез булганда, аяз булыр күкләребез,**
**Көн кояшлы, айлы булыр төннәребез!**
**Бик кадерле, бик кирәкле, бик тә газиз,**
**Онытмагыз, кемнәрнеңдер кемнәре сез!**
**Кемгәдер ул, кемгә әти, кемгәдер ир,**
**Тормыш йөге сезнең иңдә, сез баһадир!**
**Рәхмәтебез, хөрмәтебез иксез-чиксез!**
**Гел рәхәттә һәм хөрмәттә яшәгез сез!**
**Ир-егетләр, бәйрәмегез котлы булсын!**
**Юлларыгыз, эшләрегез һәрчак уңсын!**
**Тазалыкның ныгын бирсен сезгә Ходай!**
**Янәшәдә булыгыз сез мәңге шулай!**

**Гөлара Шәрипова**



# Герой-шагыйрь Муса Җәлил

Патриот-шагыйрь Муса Җәлилнең шигъри таланты, сугышчан батырлыгы һәм хәрби оештыру осталыгы фашизмга каршы аяусыз көрәштә бөтен тулылыгы белән ачылды. Аның исеме дөньяда үзенең Ватанына, үз халкына турылыклы булуның гүзәл символына әйләнде. Муса халыклар дуслыгы җырчысы буларак җир йөзендә зур соклану тудырды.

Муса Җәлил поэзиясе тау елгасы кебек көчле һәм ярсу да, кырыс һәм шаян да, дәртле һәм сагышлы да. М. Җәлилнең әдәби мирасы күп милләтле совет әдәбиятының кыйммәтле бер казанышы булып тора. Аның әсәрләре кешеләрдә матур, гуманистик тойгылар уята, аларны тормыштагы матурлыкны күрергә һәм шул матурлык өчен көрәшергә чакыра. Муса Җәлилнең исеме тарих битләренә алтын хәрефләр белән язылган, үзе үлсә дә, аның исеме, шигырьләре мәңгелек.

15 февраль көнне, мәктәбебездә татар теле һәм әдәбияты укытучысы Луиза Минһаҗ кызы, авыл китапханәчесе Рүзилә Равил кызы белән берлектә, әлеге истәлекле датага багышлап «Муса абый— балаларның якын дусты» исемле патриотик сәгать үткәределәр. «Тормышы җыр кебек» электрон презентациясе, «Ул-дәвернең батыр сугышчысы, ул-заманның бөек җырчысы» китап күргәзмәләре аша балалар аның тормыш юлы, балачак, үсмер еллары, иҗаты белән таныштылар, викторина сорауларына җаваплар әйттеләр.



# Туган телләр айлыгы

## Татар телен белүем белән бәхетлемен

Нинди таныш моңлы көй бу?
Тукай җыры – “Туган тел”.
Истән бер дә чыкмый торган
Халык көе – “Туган тел”.

Һәр кеше өчен иң якыны, иң мөһиме – ул туган теле! Минем туган телем – татар теле. Мин тугач, әниемнең назлы итеп “балам” дигән сүзе дә, беренче тапкыр әйткән “әни” сүзе дә туган телемдә булган. Туган тел! Бу сүз һәркем өчен кадерле, газиз! Ул Ватан, туган җир, ата- ана сүзләре белән бергә торган бөек, изге һәм кадерле сүз!

Иң элек бу тел белән Әнкәм бишектә көйләгән,
Аннары төннәр буе әбкәм Хикәят сөйләгән.

Туган тел турында безнең бөек шагыйребез Габдулла Тукайдан да матур итеп әйтүче юктыр. Күпме мәгънә салынган бу шигырь юлларына.

Минем туган телем – татар теле. Мин кечкенәдән бу телдә иркен сөйләшәм. Әнием миңа татар телендә бишек көйләре көйләгән, татар әкиятләрен сөйләгән. Хәзер, зур үсеп житкәч тә, мин татар эстрадасы артистлары жырларын рәхәтләнеп тыңлыйм. Татар халкының кызыклы, бөек шәхесләре, театр дөньясы, сәнгате турында күбрәк белергә тырышам. Мәктәп тормышындагы туган телемә кагылышлы чараларны яратам.

Минем өчен туган телеңне белмәү – бик кызганыч күренеш. Моның сәбәбе – гаиләдә үз телеңдә сөйләшү мөмкинчелеге булмау, дип уйлыйм. Бу яктан мин үземне бик бәхетле кеше дип хис итәм, чөнки барлык туганнарым белән туган телемдә сөйләшә алам. Һәм шуның өчен дә ата-анама, дәү әниләрем белән дәү әтиләремә рәхмәтлемен.

*Латипов Самат*
*8 сыйныф укучысы*

## Туган телдә сөйләшик.

Туган тел һәр кеше өчен кадерле һәм газиз була.Ә безнең өчен татар теле кадерле һәм газиз,чөнки без-татар балалары.Татарча безнең телебез ачылган,без татарча бишек көйләре,әкиятләр тыңлап үскәнбез.Шуның өчен дә ул безгә бик якын.Ана телем-туган телем!

Татар теле-татар халкы өчен уртак милли тел.Бу телдә дөньядагы дистә миллионга якын татар халкы үзара аңлаша,аралаша.

Мин үз телемне бик яратам.”Туган телне кадерләгән халык кына кадерле,абруйлы булыр”ди татар халык мәкале.

*Шакирҗанова Ралинә*
*4 сыйныф укучысы*

# Туган телләр айлыгы

## 21 нче февраль – Халыкара туган тел көне

Көндәлек тормышта без еш кына үзебез сөйләшә торган телне яки телләрне табигый бер нәрсә итеп кабул итәбез. Гаять зур әһәмияткә ия телебез тормыш-көнкүрешебезнең аерылгысыз бер өлеше булып тора. Фикерләү, тәртип һәм үзебезнең тормышыбызның рәвешенә, ысулына әйләнә. Шуңа күрә дә без аның төп функциясен - нәкъ менә аралашу һәм аңлашу функциясен онытып җибәрәбез. Туган тел беренче мәртәбә әйләнә- тирә мохитен танып-белергә һәм киңрәк планда дуслар, мәктәп белән аралашуда ярдәм итә торган тел ул. Бу тел - сабыйлык, изге гаилә тәҗрибәсе, башлангыч социаль мөнәсәбәтләр теле

Дөньяда 6000 нән артык телдә сөйләшәләр. Аларның һәрберсе авазлар, мәгънәләр һәм грамматик кагыйдәләрнең катлаулы системасыннан тора. Һәр кешенең беренче көннән үк туплый башлаган хәзинәсе - туган тел. Һәр милләт кешесе өчен иң матур, иң кадерле тел - үзенең туган теле. Билгеле булганча, безнең татар телебез ЮНЕСКО тарафыннан бөтен дөнья халыкара аралашу теле дип саналган 14 телнең берсе. Татар телендә арлашабыз икән, димәк, татар милләте яши, үсә. Милләтебезнең югалмавы, телебезнең үсүе безнең кулда.

21 февраль - Халыкара туган тел көне буларак билгеләп үтелә. Шул уңайдан мәктәбебездә «Тел - тарих көзгесе » исемле әдәби - музыкаль кичә узды. Татар теле укытучысы Габдрахманова Л.М. һәм китапханәче Авхадиева Р.Р. туган телебез турында сөйләделәр, укучылар туган телгә багышланган шигырьләр сөйләделәр.

*Әгъзәмов Илсаф*
*7 сыйныф укучысы*

## ТАТАР ХАЛЫК ӘКИЯТЛӘРЕ

Татар халкы- әкиятләргә бай халык. Әкиятләрдә ялкаулык, эш сөймәү кебек сыйфатлар ае-руча көчле ирония белән сүрәтләнә, хезмәт сөймәүчеләр хурлыкка калдырыла, аларга карата тискәре караш тудырыла. Әкиятләр балаларда матурлыкка, изге эшләргә соклану, усал-лыкка, явызлыкка нәфрәтләнү, шулай ук яклаучысызларны кызгану, кайгырту кебек хисләр тәрбияли. Әхлак тәрбиясе бирүдә бер мөһим бурыч булып аларны көндәлек тәртип ка-гыйдәләренә төшендерү, ияләштерү, шул кагыйдәләрнең аңлы рәвештә үтәлүенә ирешү тора. Алай гына да түгел, бала әлеге кагыйдәләрне көндәлек тормышында файдалана, куллана белергә, кирәкле күнекмәләр алырга тиеш.

Әкиятләрне театральләштергәндә балаларда әхлак тәрбиясе ныгытыла: балалар өлкәннәр белән исәнләшергә, саубуллашырга өйрәнәләр, ягымлы сүзләр белән бер-берсенә эндәшәләр. Иң якын кешене-әнине борчымаска өйрәнәләр. Һәр әйбернең үз урыны барлыгын һәм аны һәрвакыт урынына куярга өйрәнәләр. Өлкәннәр хезмәтен хөрмәтләргә, хезмәт эшчән-легендә катнашырга омтылу һәм өлкәннәргә ярдәм итәргә теләк уяту теләге тәрбияләнә. Шул максаттан укучылар белән әкиятләрне сәхнәләштереп ачык чара оештырдык. Укучылар да актив катнашып үзләренең актерлык талантларын үстерделәр.

## БӘЙРӘМНӘРДӘН КҮРЕНЕШЛӘР









# Әфган – йөрәк ярасы

Әфганстан. Күпләрне тетрәндергән сүз бу. Леонид Брежнев Әфганстанга совет гаскәрләре кертелү турындагы хәбәрне Үзәк телевидение буенча 1979 нчы елның 25 нче декабрендә игълан итте. Фәкать 1988 нче елның 15 нче маенда гына чит илдәге гражданнар сугышыннан совет гаскәрләре чыгарыла башлады һәм, ниһаять, 1989 нчы елның 15 нче февралендә соңгы совет солдаты Әфганстан чиген атлап чыкты. 9 ел 51 көн буена барган сугыш булды бу җирдә.

Еллар үтү белән күп вакыйгалар хәтердән җуела. Әмма без тарихтагы бу кайгылы көннәрне онытырга тиеш түгелбез. Гомерләренең иң матур вакытында һәлак булган егетләребезнең намус һәм хәрби бурыч төшенчәләрен үзләренең тормышыннан да өстенрәк куйганнары өчен горурлану тойгысы кичерәбез. Үлгәннәр хәтере исәннәрдә яши.

Солдат сугышны үзе сайламый, ул сугышны игълан итми. Бары тик ул, биргән антына һәм хәрби бурычына тугрылыклы калып, югарыдан бирелгән приказны гына үти. Аның каһарманлыгы, батырлыгы, Ватанга ихтирамы нәкъ әнә шунда күренә.

Әфган сугышында безнең егетләребез дә катнашты: Тимашев Фәнис Илгиз улы 1983-1985 нче еллар, Шакирҗанов Дамир Зәки улы 1985-1987 нче еллар, Галиуллин Зиннур Хәлил улы 1980-1982 нче еллар, Мөхәммәтханов Фоат Мостафа улы 1984-1986 нчы еллар (хәзерге көндә вафат). Әлеге әфганчыларны һәм махсус хәрби операциядә катнашучы Латипов Азат Шамил улы белән аның хатыны волонтер Латипова Алинәне чакырып зур бәйрәм оештырдык.

*Хәйриев Нәфис*

*7 сыйныф укучысы*







# Гражданлык-патриотик айлык

Яшь буынга патриотик тәрбия бирү хөкүмәтебез тарафыннан төзелгән аерым программа нигезендә алып барыла. Безнең Гариф Ахунов исемендәге Казанбаш төп гомуми белем бирү мәктәбендә дә укучыларга гражданлык-патриотик тәрбия бирү юнәлешендә күпкырлы эшләр оештырыла. Бу чараларның асылы - туган илгә мәхәббәт тәрбияләү. Балаларга дөрес тәрбия бирү өлкәсендә күптөрле алымнар кулланыла. Соңгы вакытта укыту-тәрбия өлкәсендә яңалык булып килеп кергән информацион технологияләр никадәр алдынгы, отышлы, уңайлы булса да, вакыйгаларны, гадәттән тыш хәлләрне, хәрби конфликтларны, сугышны үз күзләре белән күргән, анда катнашкан ветераннар, авылдашларыбыз чыгышлары һәм алар белән очрашулар үзенең актуальлеген хәзер дә югалтмый.

Һәр елны, февраль ае мәктәбебездә гражданлык-патриотик тәрбия айлыгы итеп билгеләп үтелә. Шушы айлык кысаларында мәктәбебездә ел саен Әфганстанда һәм кайнар нокталарда хезмәт иткән егетләр белән очрашу-кичәләр, спорт уеннары, бәйгеләр оештырыла. Мондый очрашулар чынбарлыкны дөрес күзалларга, авырлыклардан курыкмаска, хәрби антына һәрвакыт тугры калырга, туган җиреңне, Ватаныңны яратырга кирәклеген аңларга ярдәм итә. Яшь буынга физик яктан чыныккан һәм сәламәт булырга кирәклеген өйрәтә. Ватан каршындагы изге бурычларын үтәп, хәрби хезмәт срогын тутырып кайткан егетләребез белән очрашу кичәләрен 8-9 сыйныф укучылары яратып кабул итәләр, чөнки бу матур, таза, үз-үзләренә нык ышанган егетләр, кичә генә безнең арабызда укыган укучылар иде. Аларга карап сокланмый мөмкин түгел. Армия хезмәте аларны физик яктан чыныктырган, мораль яктан ныгыткан, дөньяга үз карашлары формалашкан. Алар үз сүзләрен, фикерләрен дөрес итеп, курыкмый әйтә алучы чын ир-егетләр булганнар. Аларның армия хезмәте, солдат тормышы, хәрби дисциплина төшенчәләрен, илебез кораллы көчләренең куәтен, хәрби техникаларның көчен, горурланып сөйләүләре укучыларда зур кызыксыну уята. Очрашу барышында укучылар үзләрен кызыксындырган сорауларга җаваплар алалар. Мәктәбебездә 21 февраль көнне Ватанны саклаучылар көне уңаеннан кичәгә хәрби хезмәттә булып кайткан укучыларыбызны, укучыларның әтиләрен, бабайларын чакырдык. Очрашу бик җылы, патриотик рухта узды.

*Тәрбия эшләре буенча директор урынбасары Рәхимова Р.З.*



